**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево 422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевский урамы, 23 нче йорт Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

---

2020 елның 15 сентябре 1848 номер

## КАРАР

**Столбище авыл җирлеге Усад авылы территориясен ызанлау проектын әзерләү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 42, 45, 46 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставы белән, территориянең тотрыклы үсешен тәэмин итү, планлаштыру структурасы элементларын (кварталлар, микрорайоннар, башка элементлар) бүлеп бирү, капиталь төзелеш объектлары урнашкан җир кишәрлекләре чикләрен, линияле объектлар төзү һәм урнаштыру өчен билгеләнгән җир кишәрлекләре чикләрен билгеләү максатларында, карар бирәм:

1. Лаеш муниципаль районында, Столбище авыл җирлеге, Усад авылы, кадастр номерлары 16:24:150302:1180, 16:24:150302:1181, 16:24:150302:2026, 16:24:150302:1177, 16:24:150302:1178, 16:24:150302:1170, 16:24:150302:1172 булган җир кишәрлекләрендә территорияне ызанлау проектын әзерләргә.
2. 2020 ел дәвамында Лаеш муниципаль районында, Столбище авыл җирлеге, Усад авылы җирендә күрсәтелгән территорияне планлаштыру һәм ызанлау проектын эшләү срогын билгеләргә.
3. Территорияне планлаштыру һәм ызанлау документларын әзерләү һәм тоту тәртибе турындагы тәкъдимнәр Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы башкарма комитеты тарафыннан эш көннәрендә түбәндәге адрес буенча кабул ителә: Татарстан Республикасы, Лаеш шәһәре, Чернышевский ур., 23 й..
4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча, Лаеш муниципаль районының http://laishevo.tatarstan.ru рәсми сайты һәм «Кама ягы» (Камская новь) район газетасында бастырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы И.П. Шитов